Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 10
(10)

8 декабрь
2011 ел

## • Ике авыз сүз

5 декабрь көнне чираттагы ректорат утырышы узды. Көн тәртибенә КФУның Инженерия институты презентациясе (инновацион эшчәнлек буенча проректор Н.Кашапов), фәлсәфә факультетының Үсеш программасын тормышка ашыру (факультет деканы М.Щелкунов), КФУның Үсеш программасын тормышка ашыру буенча традицион хисап (икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин), 2012 елга кабул итү кампаниясенә әзерлек (Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе С.Ионенко) кебек мәсьәләләр куелган иде. Шулай ук тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов ректор И.Гафуров җитәкчелегендәге КФУ делегациясенең Страсбург университетына баруы турында чыгыш ясады.

Утырыш башында уку-укыту эшләре буенча проректор Р.Минзарипов КФУ укытучылары, хезмәткәрләр һәм студентларның РФ Дәүләт Думасына сайлауларда катнашу нәтиҗәсе белән таныштырды. И.Гафуров бу эштә актив катнашкан һәр кешегә рәхмәт сүзләре җиткерде.

Алга таба Н.Кашапов ясаган чыгышта Инженерия институты турында сөйләнде. Ул ике бинада урын алачак. Берсе – С.Сәйдәшев урамы, 12 нче йортта, икенчесе К.Тинчурин урамы, 31 нче йорттагы бинада урнашачак. Яңа институт хезмәт хакы фондлары һәм финанслау чыганаклары өлкәләре өчен белгечләр әзерләячәк. И.Гафуров институт нинди белгечләр чыгарачагына тагын бер кат игътибар итәргә кушты. Алар хезмәт базарында кирәк булачакмы? Шулай ук КФУда ачылачак бүлекләрне тикшерү өчен, эксперт советы төзү турында әйтте.

М.Щелкунов һәм М.Сафиуллин ясаган хисаплар бик яхшы картина тудырды. Мәсәлән, Үсеш программасында күрсәтелгән индикаторларны фәлсәфә факультетының бастырылган фәнни язмалары сан ягыннан узып та китә. 2013 елда «Теология» дигән яңа юнәлеш ачу да планлаштырыла.

С.Ионенко «Кабул итү волонтеры-2012» проекты, КФУда уза торган интернет-олимпиада нәтиҗәләре турында җиткерде. Л.Латыйпов чыгышында Европадагы иң борынгы уку йортларының берсе - Страсбург университеты (Франция) турында сөйләде. Анда фәнни премияләр лауреаты, Нобель премиясенә кандидат, профессор, КФУда белем алган М.Йосыпов эшли. Шулай ук ике аспирант стажировка үтә. И.Гафуров әлеге вузның 2009 елда составына ике уку йортын кабул иткәннән соң, «икенче сулыш» алуын әйтте. «Без дә шул юл буенча барабыз», – диде һәм андый уку йортлары белән хезмәттәшлек итәргә кирәклегенә басым ясады. Чит илдә стажировка үтеп, туган вузына кайтырга теләгән студент һәм аспирантларга матди ярдәм итү системасын булдырырга кушты: «Андый кешеләргә КФУда да үз юнәлешләре буенча үсү мөмкинлеге тудырылырга тиеш», – диде.

• • • •

2 декабрь көнне университетка Schlumberger («Шлюмберже») нефтесервис компаниясеннән делегация килде. КФУ күптәннән студентларны эшкә урнаштыру, фәнни эшчәнлек буенча алар белән хезмәттәшлек итә. Киләчәктә бәйләнешләрне тагын да ныгыту, белем бирү системасына үзгәрешләр кертү, КФУ базасында Schlumberger үзәген ачу, инновацион продуктлар әзерләү буенча уртак эш алып бару турында сүз булды.

• • • •

Казан университетының геология музее – Россиянең XVIII гасыр ахырында югары уку йортларында оеша башлаган иң борынгы һәм тарихи музейларының берсе. Ул Казан Император университетының беренче Уставы нигезендә 1804 елда ачыла. Файдалы казылмалар, минераллар белән беррәттән, борынгы геологик җиһазлар да урын алган. Биредә лекцияләр генә түгел, гамәли дәресләр дә уза. Минералогия залында Җирнең бөтен байлыклары белән танышырга мөмкин. Моннан тыш, сирәк очрый торган метеоритлар күргәзмәсе дә эшли. Экспозициядә 1951 елда Аргентинада табылган дөньядагы иң матур Esquel метеориты да бар. Музейда шулай ук Бозлык дәверендә табылган хайван калдыкларын да күрергә мөмкин.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




Энҗе Ибраһимова фотосы

# Өч төп бүләк – КФУда

**Энҗе ИБРАҺИМОВА,**
хәбәрче

Узган җомгада Казанның Пирамида күңел ачу үзәгендә «Ел студенты-2011» бәйгесенең финалы узды. Чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин һәм КФУ ректоры Илшат Гафуров катнашты.

Быел конкурска Татарстанның югары һәм урта уку йортларыннан 268 гариза кабул ителгән. Финалга үткән һәр студент, оешма инде җиңүче – алдынгылар рәтендә. Җиңүчеләрне 16 номинация буенча тәбрикләделәр. Иң-иңнәр арасында безнең уку йортыннан «Ел журналисты» исеменә Зөлфия Таразова лаек булды. Икътисад һәм финанс институты студенты Андрей Петухов «Елның җәмәгать эшлеклесе» булды. «Иҗади коллектив» номинациясендә КФУның «ШТОРМ» бию коллективы җиңү яулады.

Бәйгенең төп җиңүчесен игълан итәр алдыннан, ТР Президенты Рөстәм Миннеханов: «Бүген бездә бик зур чара. Республикабыз талантлы яшьләргә гаҗәп бай. Бу исемлеккә син дә керә аласың! Бары ялкаулыкны тырышлык белән алмаштырып, чын күңелдән эшкә бирелергә генә кирәк! Алтын җирдә аунап ята торган заман түгел», – диде һәм җиңүче дөньяның теләсә кайсы югары уку йортында стажировка үтү мөмкинлегенә ия булуын әйтте.

Чараның иң зур бүләге – «Ел студенты» исеменә Казан федераль университетының Икътисад һәм финанс институты студенты Марсель Нигъмәтҗанов лаек булды. Ул уку һәм эш, спорт һәм җәмәгать эшләрен бергә алып бара белә. Җиңүче уңышының нигезен бөтен җирдә дә актив булу, инициатива күрсәтү, үз фикереңне төгәл билгеләп, яңа идеяләр тәкъдим итүдә күрә. Марсель шулай ук «клуб пиджагы», шарф, статуэтка һ.б. бик күп истәлекле бүләкләргә ия булды.

Традиция буенча төп җиңүче «Гран-при – Ел вузы» номинациясен игълан итә. Быел ул исемне Казан милли-тикшеренү технология институты алды. Җиңүчеләрне билгеләү, котлау сүзләре республика студентларының иң яхшы иҗат коллективлары чыгышы белән үрелеп барды.

Әлеге бәйге елдан-ел студентларда зур кызыксыну уята. Мондый чараларга җөмһүриятебез җитәкчеләренең битараф булмавы – уңай күренеш. Җиңүчеләрдән күреп, башкалар да алга омтыла. Үзеңне күрсәтү, тәҗрибә уртаклашу, дуслык җепләрен ныгыту өчен дә менә дигән мөмкинлек бит!

## • «Шигъри Сабантуй-2011»

# «Батыр»лар мәйдан тотты

**Булат ИБРАҺИМ,**
хәбәрче

«Борын-борын заманда түгел, моннан илле-алтмыш ел элек Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына әдәби түгәрәк килеп кергән, ди»...

Менә шуннан башланып китә дә инде ул «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенең күңелле, мавыктыргыч, маҗаралы сәхифәләре. Күпме шагыйрь-язучыларның даһилыгын ачып бирде бу түгәрәк. М.Әгъләм, Зөлфәт, Р.Мөхәммәдиев, Р.Зәйдулла, Р.Миңнуллин, И.Иксанова һ.б. – барысы да «Әллүки» мәктәбен узган иҗатчылар.

Сүзне ничектер ерактанрак башладым кебек, кыскасы, ишек алдында 2011 елның карлы декабре. 7 ел элек шундый ук карлы кыш аенда «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенең җитәкчесе Г.Гыйльманов һәм ул вакыттагы иң актив «әллүкиче» Л.Шәех зур шигырь бәйрәмен оештыру теләге белән яналар.

**Ахыры 3нче биттә.**

Ахыры 3нче биттә.



Энҗе Ибраһимова фотосы

## Атнаның өч ачышы

2 декабрь көнне Казан университетында Технологик үзәк ачылды (Зур Кызыл ур., 4 нче йорт). Вакуум-плазма технологияләре, метрология һәм стандартлаштыру бүлекләре инде фәнни җиһазлар белән тәэмин ителгән. Озакламый калган бүлекчәләр дә җиһазландырылачак. Ректор И.Гафуров әйтүенчә, Технологик үзәк КФУ һәм республика сәнәгате, авыл хуҗалыгы арасында тыгыз бәйләнешләр булдыруга йөз тота. Аерым бер тармак умартачылык өлкәсендә заманча технологияләргә бәйле мәсьәләләрне хәл итү белән шөгыльләнәчәк.



Алексей Леонтьев фотосы

Шул ук көнне КФУда Фармацевтика фәнни-белем бирү үзәге медицина химиясе бүлегенең лабораторияләре ачылды. Биредә «Татхимфармпрепараты» ААҖ белән тыгыз бәйләнештә яңа дару һәм субстанцияләр җитештерү эшен җәелдерү күздә тотыла.



Алия Галимуллина фотосы

***

Казан университетының биохимиклары зур ачыш ясады: агрессияне төкерек ярдәмендә билгеләп булачак. Моның өчен кешегә тест-тасманы ялап алу җитә.

«1,5 мең казанлының төкереген тикшердем. Алар арасында психиатрия үзәкләре пациентлары да, полиция мәктәбендә белем алучылар да, мәктәп укучылары да бар», – ди КФУның биохимия кафедрасы доценты, 2004 елдан бирле бу юнәлештә фәнни эш белән шөгыльләнүче Әлфия Фәттахова.


Галимә әйтүенчә, мәсәлән, наркотик кулланучыларның 67 процентында махсус фермент (фәнни телдә «моноаминоксидаза А» дип атала) бик түбән дәрәҗәдә, шуның аркасында кеше наркотикларга тартыла икән. Мәктәп укучыларының исә якынча 7 проценты агрессия белән интегә. Ул тора-бара депрессиягә әйләнә. Яшүсмер «ярдәм сорап» алкоголь яки наркотикка мөрәҗәгать итәргә, хәтта җинаять эшләргә мөмкин. «Кыз балаларның әти-әниләрен тынычландырасым килә, чөнки бу авыру белән күбрәк малайлар интегә. Шуңа күрә аларны, көч-куәтен дөрес файдалансын өчен, тиешле юлга кертеп җибәрергә кирәк. Андый балалардан бик яхшы спортчылар, иҗат кешеләре чыгачак», – ди галимә.

Бүгенге көндә әлеге тест-тасманы күпләп чыгару турында сүз бара.

• Фән дөньясында

# «Кояшны алыштырып булмый...»

**Ленар ХАММАТОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты



Узган атнада университетта «Исламны яңарткан агымнар» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Кышның беренче көнендә сәгать тугызда башланып киткән бу конференция икенче көнне сәгать биштә тәмамланды.

Конференция бер генә ил галимен дә битараф калдырмагандыр дигән фикергә килдем мин. Ник дигәндә, үзебезнең галимнәр белән беррәттән, Мисыр, Малайзия, Иордания, Франция кебек ил галимнәренең чыгышларын тыңларга насыйп булды. Чарада Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, ИСЕСКОның Россиядәге җитәкчесе Сәид Кямилов, Россия ислам университеты ректоры Рафыйк Мөхәммәтшин, Гарәб Федерациясе университетларының генераль сәркатибе Солтан Әбү Ураби әл-Гәдвәни, Мәскәүдәге гуманитар һәм җәмгыяви белемнәрнең франк-россия үзәге директоры Жан Ридвани, Малайзиядәге халыкара ислам университетының Ислам фикере һәм цивилизациясе институты директоры Хәсән Әхмәд Ибраһим катнашты.

Солтан Әбү Ураби әл-Гәдвәни исламдагы күп кенә проблемаларны фиркалардан күрә. XXI гасырны уку-укыту системасына яңа таләпләр куюны сорый торган заман, дип искәртте ул. «Без уку мәсьәләсен бик җентекләп өйрәнергә тиешбез, чөнки белем – ул һәрбер кеше бара торган бер юл кебек. Ә университетларыбыз һәр кешегә яшәү стимулы бирә торган уку йорты булырга тиеш», – дип сүзен тәмамлады.

Дамаск (Сүрия) университеты галиме Тәүфыйк Рамазан Буты сүзен: «Зур хөрмәткә ия булганы – үзегезнең тамырларыгызны һәм асылыгызны югалтмау, – дип башлады. – Әлбәттә, алга китеш булсын өчен, яңарыш кирәк. Ләкин традицион кыйммәтләрне алар иске булганга гына читкә этәрү, ә яңаларны алар яңа булганга гына кабул итү дөресме икән? Кайбер тарихи кыйммәтләрне үзгәртергә һич ярамый. Мәсәлән, кояшны без алыштыра алмыйбыз, ләкин шул ук вакытта аның энергиясен яңача куллану мөмкин гамәл. Бишкә бишне кушкач, ун булганын һәрбер кеше белә, бу элеккедән килгән закончалык. Шуның мисалында, кайбер элеккеге терминнарны үзгәртергә дә, алыштырырга да ярамый. Әгәр дә сүз берәр җирлекнең исламга кагылган аерым гореф-гадәтләре турында бара икән, бу очракта аларга үзгәреш кертү мөмкин хәл».

Һәрбер галим яңарыш кертүне тамырдан күтәргән. Бу проблеманы аерым бер халыкныкы яки милләтнеке итеп түгел, бәлки, глобаль проблема буларак күзаллап, чишү юлларын эзләгән. Һәм үзләренең эшләрен халык аңларлык гади телдә язарга тырышканнар: матур сүзләр матур булып күренәләр генә, ә безгә, галимнәрнең сүзләренә колак салып, ата-бабаларыбыз, Аллаһы Тәгалә һәм пәйгамбәребез (с.г.в.) өйрәткән юлдан тайпылмыйча барырга гына кирәк.

• Тел бәйгесе

# Полиглотлар ярышы

**Наилә БАДЫКШАНОВА,**
ksu.ru сайты хәбәрчесе

6 декабрь көнне «Уникс»ның кече залында «Полиглот» конкурсы ачылды. Казан, Пермь, Улан-Удэ, Саратов, Пенза шәһәрләреннән тел белгече булмаган 250 студент чит телләр буенча көч сынашты.

Конкурсны ТРның Студентлар лигасы һәм КФУның Тел институты ТРның Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Югары уку йортлары ректорлары советы белән берлектә оештыра.

Конкурс ике номинациядә үтте. Беренчесендә конкурсантлар берничә чит тел (инглиз, немец, француз, испан) белү, икенче номинациядә билгеле бер тел буенча ярыштылар.

Катнашучыларны чит ил кунаклары да, КФУ укытучылары да берничә телдә сәламләде. Жюри рәисе Фаина Ратнер: «Европаның девизы – туган тел плюс ике чит тел. Укытучылар да Россия вузларында белем алучы студентларның ике чит тел өйрәнүен тели», – диде. Студентлар лигасы президенты Тимур Сөләйманов җиңүчеләргә тапшырылачак бүләкләр белән таныштырды. I урынга – Malvern House (Великобритания) мәктәбенә ике атналык стажировка, II урынга – Европа илләре буенча сәяхәт, III урынга мәдәни чарага ике билет тапшырылачак. Шулай ук чит ил кунаклары да җиңүчеләргә зур бүләкләр әзерләгән.

«Ике һәм аннан да күбрәк тел белгән кешеләргә мин сокланып карыйм. Биредә иң яхшы полиглотлар билгеләнәчәк, ләкин һәркем үзе өчен җиңүче булырга тиеш», – диде уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов.



Алия Галимуллина фотосы

• Искә алу

# Сәйдәш моңы

**Гөлчәчәк СӘЛИМҖАНОВА,**
сәнгать бүлеге аспиранты



2 декабрь көнне Филология һәм сәнгать институты сәнгать бүлегенең концертлар залында татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салучы бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевне искә алу кичәсе үтте.

Кичәдә сәнгать бүлеге мөгаллимнәре профессор Рәгъде Халитов, Татарстанның халык артистлары Лидия Әхмәтова, Миңгол Галиев, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклеләре Әнисә Абдуллина, Мулланур Габитов, Бөтенроссия конкурслары лауреатлары Зөлфия Ибраһимова, Екатерина Коврикова, Дамир Габдрахманов, Дамилә Надырова, Зөлфия Шәрифуллина, халыкара конкурслар лауреаты Виктор Киреев, Фәнис Мөхтәров, Гөлчәчәк Сәлимҗанова һәм, әлбәттә, сәнгать бүлеге студентлары катнашты. Сәйдәш әсәрләре, Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасы белән үрелеп, тамашачылар күңелендә илаһи моң булып яңгырады. Кичә дәвамында композиторның тормыш юлы, иҗатына кагылышлы кызыклы мәгълүматлар җиткерелде. Салих Сәйдәшев күпкырлы талант иясе: тиңдәшсез композитор, татар музыкантлары арасында беренче дирижер, оста пианист, тәҗрибәле педагог та. Аның әсәрләре – халыкчан моңнардан тукылган якты иҗат. Көйләре ягымлы аһәңнәре белән күңелне биләп ала, якын һәм аңлаешлы булуы белән аерылып тора.

Салих Сәйдәшев иҗатын яраткан, аны халыкка җиткерүдә зур эш башкарган, композиторның музеен ачу, һәйкәл кую, Казанның Зур концертлар залына аның исемен бирү өлкәсендә аеруча да актив булган Салих Шамов «Ватаным Татарстан» газетасына биргән интервьюда шактый кызыклы мәгълүматлар җиткерә. «Гөлнара» балетының язылу тарихына бәйле өлеше аеруча да игътибарга лаек. «Куйбышев сусаклагычы төзелеше башланганчы, су астында кала торган җирләрне тарихи кыйммәте ягыннан тикшерү башлана. Шул елларда галим Хәйри Гыймади Салих абыйга Болгар җирләренә барып кайтырга тәкъдим ясый. 1949 елны беренче экспедициягә баралар. Тәэсирләнеп кайткан композиторга Хәйри абый Болгар тарихына багышланган күләмле әсәр язарга тәкъдим итә. Менә шулай Салих Сәйдәшев һәм Гай Таһиров «Гөлнара» балетын язалар. Бу әсәр өйдә торган чиләкләрдә су катарлык суыкларда толыплар бөркәнгән килеш язылды, дип искә ала алар соңыннан. Тик аңа сәхнәгә чыгарга насыйп булмый. Ә бит башта әсәр сәхнәләштерелә дип вәгъдә итәләр. Әмма 1948 елда махсус карар нигезендә тарих фәне дәреслекләреннән Болгар чоры сызып ташланды. Ни өчен дигәндә, бөтен төрки халык Болгар тарихына берләшер дигән шик туды. Шулай ук Алтын Урда тарихы да тыелды. Шул сәбәпле, 1949 елда Салих Сәйдәшев белән Гай Таһиров КГБга чакырыла һәм каты кисәтү ала. Либретто исә архивка озатыла. Гай Таһиров шуңа күрә аның хакында туксанынчы елларда гына искә төшерә».

«Сәйдәш язмышы – гыйбрәт тә, горурлык та, алыр сабак та! Нечкә җаннар – талантлар белән сак булыгыз, дигән набат та!» – дип язган иде шагыйрь Равил Фәйзуллин. Композитор иҗаты һәм тормышы турында кызыклы истәлекләр табылып тора. Өйрәнер байлык әле шактый.

Уку йортыбызның бер бинасы (элекке ТДГПУның төп бинасы) каршында Сәйдәшкә һәйкәл куелды. Һәм ул моңа лаек!

● «Шигъри Сабантуй-2011»

# «Батыр»лар мәйдан тотты

**Башы 1нче биттә.**

Татар халкының көтеп алынган иң зур җәйге бәйрәме – Сабантуй. Нигә соң әле шигъриятнең дә үз Сабантуен оештырмаска? Кыскасы, 2004 елда татар шигырен сөюче студентларның иҗат бәйрәме – Шигъри Сабантуе дөньяга килә. Еллар артыннан еллар томырылып чаба бирәләр, «Шигъри Сабантуй» шигърият мәйданына яңа яшь шагыйрьләрне чыгара. Ленар Шәех, Йолдыз Миңнуллина, Рифат Сәлах, Лилия Гыйбадуллина, Булат Ибраһим, Эльвира Һадиева, Фәнил Гыйләҗев... Әлбәттә, бу исемлекне озак дәвам итеп була.



Энҗе Ибраһимова фотосы

2010 елдан башлап «Шигъри Сабантуй» атналык бәйрәмгә әверелде. Тик шулай да атнаның иң көтелгән вакыйгасы – автор-башкаручылар бәйгесе. Былтыргы «Сабантуй» шагыйрь Хәсән Туфанның тормышына һәм иҗатына нигезләнсә, быелгы бәйрәм атналыгы бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 125 еллыгына багышланган иде.

«Шигъри Сабантуй»да катнашырга төрле уку йортларыннан 50 кеше теләк белдерде, хәтта Пенза өлкәсеннән дә килгәннәр иде. Бәйгенең яңалыгы булган «Яшь батыр» номинациясе бәйрәмгә яңа сулыш өрде. Ул мәктәп укучыларының чыпчын шигъри көрәше булды. Көрәш мәйданына Казан, Яр Чаллы шәһәре, Яшел Үзән, Кукмара, Буа, Мамадыш районы мәктәпләреннән укучылар җыелды. Барлыгы 18 эш кабул ителгән иде.

Шигъри бәйрәмгә ямь өстәп, Филология һәм сәнгать институты кызлары һәм егетләренә ияреп, сәхнәгә җыр, җырга ияреп, бию менде. Ә менә алып баручылар сәхнәдән тамаша залына төшәргә мәҗбүр булды. Әлбәттә, ялыгудан түгел, ә җыелган тамашачы белән якыннанрак әңгәмә кору өчен...

Ниһаять, «Шигъри Сабантуй»ның иң кызган чагы – көрәш башланды. Бер-бер артлы 18 «көрәшче» студент-батырларыбыз пәйда булды. Сөйләнгән шигырьләрнең тематикасына килгәндә, әлбәттә, уртаклык күп, ләкин шул ук вакытта аерым бер табышлары да шактый. Мәйдан кызганнан кызды – һәм менә Сабантуйның иң дулкынландыргыч мизгелләре килеп җитте. Сәхнәгә «батыр»ларның исемлеге белән таныштырырга гадел хөкемдарлар күтәрелә. Быелгы бәйгенең жюри рәисе итеп танылган язучы Галимҗан Гыйльманов билгеләнгән иде. Баш хөкемдарга гадел хөкем чыгаруда шагыйрьләр һәм әдәбиятка битараф булмаучылар ярдәм итте. Араларында Ленар Шәех, Илсөяр Иксанова, Флёра Сәйфулина, Әлфәт Закирҗанов, Рифат Сәлах бар иде. Г.Гыйльманов батырларның исемлеген укый башлады.

Ярыш булгач, әлбәттә, күңел бүләк көтә. Җиңгән батырларыбыз барысы да татар классикларының китаплары һәм дипломнар белән бүләкләнде. Һәм менә шуның белән тәмам да булды. Татар халкының гимнына әверелгән «Туган тел» тамаша залыннан – сәхнәгә, сәхнәдән бөтен татар дөньясына, әдәбият, сәнгать сөючеләрнең күңелләреннән горур бер хис булып ташып чыкты. Инде мәкаләгә нокта куеп, соңгы 7 сүз: Шигърият бар, ул яшәде, яши һәм яшәячәк.

**«Ерактан торып» номинациясе:**

*I урын - Буа шәһәренең 2 нче лицей укучысы Гөлназ Газизова;*
*II урын - Түбән Камадан Алмаз Хафизов;*
*III урын - Сарманнан Раил Арсланов һәм Мамадыш районы Көек-Ерыкса авылыннан Гүзәл Зиннурова.*
*Жюри симпатиесе (шулай ук III урын) – Пенза өлкәсе Каменский районы Кикин авылы гомумбелем бирү урта мәктәбе укучысы Альбина Акжигитова.*

**«Яшь батыр» номинациясе:**

*I урын - Яшел Үзән шәһәреннән Эльвина Гыймадиева һәм Гөлия Абдуллина;*
*II урын - Казан шәһәреннән Ләйсән Шәрәфетдинова һәм Кукмарадан Алинә Бәдретдинова;*
*III урын - Яшел Үзән шәһәреннән Рәзилә Җиһаншина, Кукмара районы Зур Сәрдек авылыннан Ришат Минемуллин,Казан шәһәреннән Айгөл Баһавиева һәм Гөлнара Хәсәнова.*

**«Сабантуй батыры» номинациясе:**

*I урын - КФУның татар филологиясе бүлеге студенты Гөлназ Яппарова;*
*II урын - шул ук бүлек студентлары Руфинә Габдрахманова һәм Айсылу Ибраһим;*
*III урын - шул ук бүлек студентлары Светлана Гыйләҗева һәм Гөлназ Гатауллина, Казан дәүләт энергетика университеты студенты Сөмбел Гайфетдинова һәм Казан кооперация институты студенты Дания Нәгыймуллина.*

● Өйрәтәләр мәктәпләрдә

# Ялгыш язмышлар

**Сөмбел ӘХӘТОВА,**
Көнчыгышны өйрәнү институты студенты

«Язмыш синең тез астыңа китереп сукса, егылмас өчен, якасынаябыш!» Казан шәһәренең яшүсмерләр һәм тәртипләре тайпылышлы булган балалар өчен махсус белем бирү мәктәбенең тимер ишекләрен ачып керүгә, күренекле язучы Фәнис Яруллинның күпләр өчен девиз булырдай сүзләре исемә төште.



### *Белем эстәп...*

Кеше ялгышларсыз гына яшәми. Ялгышлардан сабак алып, матурлыкка, яхшылыкка омтылырга кирәк. Олы кешеләр дә зур ялгышлыкларга дучар булган бу авыр һәм катлаулы заманда балаларны хаталардан саклап калу бик авыр. Бу мәктәп нәкъ менә шушы авырлыкларга тап булган, хак юлдан тайпылырга өлгергән балалар һәм яшүсмерләр өчен ачылган. Педагогик белемебезне арттыру максатыннан, Көнчыгышны өйрәнү институтының IV курс студентларын бирегә укытучыбыз Рәйсә Әфтәх кызы алып килде. Мәктәп тормышы, балаларның үз-үзләрен тотышы, тайпылышлары турында мәгълүмат тупладык.

Тимер чыбыклар белән әйләндереп алынган булуына карамастан, ниндидер бер яктылык иңдереп торган бу мәктәпкә керү без – булачак педагоглар өчен бернинди тарсыну да тудырмады. Киресенчә, тизрәк барысы белән дә танышасы, үз күзләребез белән күрәсе, өйрәнәсе килде.

### *Мәктәп буйлап сәяхәт*

Мәктәп үз эченә уку, яшәү, тернәкләндерү бинаper белән бергә футбол, хоккей, баскетбол мәйданчыкларын да сыйдырган. Ишегалды яшеллеккә күмелгән, клумба рәвешендә ясалган чәчәклекләр, кечкенә куаклар күренә. Бигрәк тә шушы мәктәпкә нигез салган, озак еллар аның директоры булып эшләгән Нәфис Галләмов истәлегенә балаларның үз куллары белән ясалган йөрәк формасындагы чәчәк клумбалары зур мәгънәгә ия.

Экскурсияне җитәкчелек урнашкан бинадан башладык. Уку-укыту үзәгендә тукталмыйча булдыра алмадык. Анда безне балаларның «Үз-үземә биш елдан соң», «Саубуллашу», «Мин монда ничек килеп эләктем» кебек хатлары җәлеп итте. Һәр балага ачылган аерым папка, индивидуаль күзәтү мәктәптәге тәрбиянең көчле булуы һәм педагогик яктан дөрес төзелгәнлеге турында сөйли. Шушы ук бинада урнашкан христиан һәм мөселман балалары өчен аерым дини бүлмәләр аларга тагын да ышаныч, көч бирә. Республика күләмендә лицензиягә ия булган бердәнбер тулы тернәкләндерү үзәге аерым игътибарга лаек: мәктәптә тәрбияләнүчеләргә стоматолог, физиотерапевт һ.б. ярдәм күрсәтә.

### *Эш тәртибе*

Мәктәпнең психологы Люция Сөембәк кызы безгә бик теләп психологик бушану бүлмәсен күрсәтте. Дивардагы «Минем тормыш шигарем», «Минем юлым – җиңү юлы» стенгазеталары ук психологның эш тәртибен ачып сала. Бу бүлмәдә балалар 7-10 кешелек төркемнәргә бүленеп эшлиләр. Һәр укучының аерым дәфтәре булу, психологик уеннар аларга зур ярдәм күрсәтә. Юрий Куклачевның «Яхшылык мәктәбе» программасына нигезләнеп эшләүче психолог Люция Сөембәк кызы безгә дә психологик тренинг үткәреп алырга булды. Бары ике генә минут барган бу тренинг, күңелнең иң нечкә кылларына кагылып, йөрәкнең иң түрендәге хисләргә салынып, барыбызның да күзләрендә яшь бөртекләре ялтыратты.

Экскурсиябезне укыту бүлеге мөдире Сергей Александрович дәвам итте. Үзләренең проблемалары, уй-хыяллары белән бүлешергә тартынмаган бу кеше балалар өчен кулыннан килгәннең барын да эшләргә омтыла. Мәктәпнең физик тәрбия залын, уку кабинетларын күрсәтте ул. Киләчәктә сәламәтләндерү буенча физик тәрбия залы булдыру, аның җиһазларын табу юлларының серен чиште.

Көн дәвамында дәресләр, дәрестән тыш үткәрелгән түгәрәкләрне карап, үзебез өчен нәтиҗә ясап утырдык. Менә бит: гади мәктәп балаларының күпчелеге ясый алмаган матур урындыкларны, йомшак мендәрләрне, кул моторикасын яхшыртуга юнәлтелгән кәгазь аккошларны бу балалар чын күңелдән яратып башкаралар. Агач эшкәртү түгәрәгендә утыручы бер малай янына килеп, сөйләшергә омтылыш ясап карадым. Тик малай гына минем белән артык сүз куертырга уйламады. Сорауларыма кырыс кына җавап бирде дә эшен дәвам итте. Аңлашыла: алар кешеләргә ышанычларын югалтканнар, күңелләрен яраламас өчен, чит-ятларны якын җибәрмиләр.

Директор кабинетында урнашкан чиксез күп грамоталар, медальләр, кубоклар мине таң калдырды. Гади урта белем бирү мәктәбен тәмамлаган элеккеге укучы буларак, минем мондый байлыкны күргәнем юк иде. Шулай ук бүлмә диварын бизәгән йолдызлар һәм балаларның фотосурәтләре, спортчыларның уен киемнәре, җиһазлар мине бик сөендерде.

Коридор буйлап атлыйм... Ике як диварда балаларның кая да булса күмәк барып төшкән фотосурәтләре, Татарстан Җөмһүрияте һәм Россия Федерациясе гимны, алар янәшәсендә шушы мәктәпнең гимн сүзләре... Гөлләр, зур якты тәрәзәләр... Барам һәм уйлыйм: «Гади мәктәпләрдә укучы балаларның күбесенә моның кадәр игътибар, тәрбия татымыйдыр. Бу дөрес микән?!»

### *Өч кагыйдәне истә тотканда...*

Сорауларыма җавапны көн азагында үткәрелгән җыелыш-әңгәмәдә таптым. Белүемчә, бу мәктәпкә балалар суд карары нигезендә килеп эләгәләр һәм иң күбе 3 ел белем-тәрбия алалар. Балаларга монда җинаятьче буларак карамыйлар. Укучы бу мәктәптән чыгып киткәч тә, аны 3 ел күзәтәләр, ярдәм итеп торалар. Барыр җирләре булмаган ятимнәрне балалар йортына урнаштыру, беренче вакытта киемсалым, кирәк-ярак белән тәэмин итүне дә үз өсләренә алалар. Бүген биредә 75 бала тәрбияләнә. Шунысы күңелле: күп кенә укучылар, срокларын тутыргач та, бу мәктәптән китәргә ашыкмыйлар, срокны арттыру өчен, судка мөрәҗәгать итәләр. Әлбәттә, мондый җылы карашны, яхшы мөнәсәбәтне суык, игътибарсыз җәмгыятьтән килгән, ялгышларга дучар булган бала тагын кайда таба ала?! Мәктәп психологы Люция Сөембәк кызы әйткәнчә, биредә мөһим 3 кагыйдә бар: янәшәңдәгеләрнең сине аңлавы, кабул итүе һәм уңай якларыңа карап бәяләве.

Аерылышканда, балаларыгыз саны һәрчак артсын, кимемәсен, дип түгел, киресенчә, алар кимесен, җәмгыятебездә таза-сау кешеләр күбрәк булсын, чөнки киләчәк шундыйлар кулында, дип теләкләребезне җиткердек.

• Халәт

# Тәҗрибә туплап...

**Илнур ЙОСЫПОВ,**
татар филологиясе бүлеге аспиранты

Татар халкын яраткан, аның телен, әдәбиятын, тарихын тирән өйрәнергә, үстерергә теләгән укучылар КФУның филология һәм сәнгать институтына укырга киләләр. Студент исеменә лаек булу өчен, нилә́р генә эшләмиләр алар: бернинди конференция, бәйге, олимпиадалар игътибардан читтә калмый. Безнекеләр арасында Казан шәһәре Мэриясе, Татарстан Фәннәр Академиясе, Оксфорд-Россия фондының стипендиатлары, ТРның һәм РФнең дәүләт стипендиясе ияләре бар.

Шулай ыгы-зыгы белән биш ел вакыт үтеп тә киткән. Шатлыклы да, бераз моңсу да... Киләчәктә язмышларыбыз ничек кенә булып бетсә дә, университет һәм аның тормышы күңелләребездә калыр. Ә иң кызыклы мизгелләр һәрвакыт күңел түрендә сакланалар.

2010 елның 28 октябрендә Удмуртия дәүләт университетында (Ижау) «Россия халыклары телләре һәм әдәбиятлары» дип аталган Бөтенроссия студентлар олимпиадасы уздырылды. Анда төрле милләт вәкилләре (башкорт, удмурт, мари, коми, бурят, якут һ.б.) көч сынап карады. Бирედә катнашу, бер яктан, зур шатлык булса, икенче яктан, зур җаваплылык. Бу олимпиаданың бер үзенчәлеге бар: монда беркем дә үзе өчен генә тырышмый (чөнки үзеңә ничек тә ярарга мөмкин). Синең олимпиада эшен ничек эшләвеңә, үзеңне ничек күрсәтүеңә карап, милләтеңә бәя бирелә. Ә безнең Казанга кайтып керәсе дә бар! Шуңа күрә без,





бар көчебезне, белемебезне эшкә җигеп, «Казан командасы» өчен тырыштык.

Аллага шөкер, ахыры хәерле булды, команда югалып калмады. Олимпиада биремнәренең берсендә өзеккә анализ ясарга кушылган иде. Безнең команданың «Анализлар бит күп төрле, без кайсын ясыйк соң? Традицион, мифопоэтик, әллә инде фәнара бәйләнеш принцибын кулланып, лингвистик анализ ясыйкмы?» дигән соравына олимпиаданы оештыручылар бер мәлгә үзләре дә югалып калдылар. Ә без бирелгән текстка үзебез белгән барлык анализ төрләрен дә ясадык. Шулай итеп, тел, әдәбият, тарих юнәлешләрендә җиңү яулап кайттык.

Бүлектә универсаль галимнәр укыта. Анда бирелә торган белем белән, республика, ил чикләрен үтеп чыгып, дөнья аренасына юл тотарга мөмкин.

Бер уйласаң, кызык та бит: әле кайчангына шундый көчле фикер ияләре, эзләнүчән һәм тынгысыз галимнәрнең тирән эчтәлекле һәм кыю фикерләргә бай лекцияләрен тыңлап утыра идек, инде хәзер үзебез дә аспирант булдык. Халкыбызның тарихын, аның шәхесләрен өйрәнәбез. Ничәмә еллардан бирле архивларда тузан җыеп яткан папкалар бүген дә әле безне куркыта. Бу битләрдә кан эзләре, күз яшьләре сакланып калган. Татар халкы тарихындагы бик күп проблемаларны яңа баштан өйрәнү таләп ителә. Әйтергә кирәк, хәзер үзебез дә остазларыбызның фәнни карашларына таянабыз. Алар кебек һәрьяклап объектив булырга тырышабыз.

Тормышта кешеләрдән өйрәнәсең, тәҗрибә аласың. Кем нәрсәгә өйрәнә, нинди остаз сайлый? Һичшиксез, әгәр дә без фәнни юнәлештә нинди дә булса уңышларга ирешкәнбез икән, беренче чиратта, бу безнең укытучыларыбызның тырышлыкларының нәтиҗәсе. Алар студент өчен күп көч куялар, күпне таләп итәләр, кирәк вакытта кырыс та, усал да була беләләр һәм һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торалар. Бик зур рәхмәт сезгә, кадерле укытучыларыбыз!

• Хушлашу



2011 елның 6 декабрендә озакка сузылган каты авырудан соң КФУның Филология һәм сәнгать институты профессоры, ТРның атказанган фән эшлеклесе, ТРның атказанган укытучысы, Халыкара төрки академия академигы Флёра Садри кызы Сафиуллина вафат булды.

Флёра Садри кызы Сафиуллина 1938 елның 24 маенда элеккеге Сарман районы (хәзерге Тукай районы) Теләнче Тамак авылында туа. КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, татар теле кафедрасында эшли башлый. Лаборант, ассистент вазифаларын башкара. Ф.Сафиуллинаның тулаем хезмәт юлы Казан университеты белән бәйле. Галимә 1992-2008 елларда татар теле кафедрасын җитәкли.

Профессор Ф.Сафиуллина – 300 дән артык фәнни монография һәм фәнни-методик хезмәт авторы. Моннан кала, ул 500 гә якын фәнни һәм укыту-методик мәкаләләре белән татар тел белеменең үсешенә зур өлеш кертте. Галимә лексикография, татар телен чит телләр аудиториясендә укыту методикасы юнәлешләрендә дә эшли, республикабызда татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертү өлкәсендә зур хезмәт куя. Галимә җитәкчелегендә чит ил һәм Россия университетлары белән фәнни-тикшеренү элемтәсе булдырыла. Ул Берлинның Азат университетындагы (Германия) Төркология институты белән хезмәттәшлек итә, Хельсинкида татар теле буенча лекцияләр укый.

Ф.Сафиуллина Каюм Насыйри исемендәге премия иясе, «Ел хатын-кызы – 2000» дигән дәрәҗәле исемгә лаек, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру комитеты әгъзасы, «Сөембикә», «Ялкын», «Мәгариф» журналларының редколлегия әгъзасы иде.

Зыялы, талантлы, кешелекле галимәбез белән хушлашу бүген сәгать 10 да икенче корпусның Мәрмәр залында уза.

• Сәламәтлек

# Каш буйыйм дип...

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Дустым Алсуның соңгы араларда күзләре гел кызара, кара-каршы утырып сөйләшкәндә, оялып, карашын читкә алып сөйләшә. Алдан бер дә игътибар иткәнем булмады, ләкин шулай да беркөнне сәбәбен туры бәреп сорарга булдым. Табиблар конъюнктивит дигән диагноз куйдылар, ди. Бу диагнозның сәбәбе дус кызымның ясалма керфекләр белән чиктән тыш мавыгып китүендә һәм әледән-әле төрле төстәге линзалар киюендә икәнен белгәч, үзем дә таң калдым...

Бүген яшьләр арасында (беренче чиратта, кызлар турында сүз бара) ясалма керфек куйдыру һәм төсле линзалар кию модага кереп китте. Шәп бит: эх дигәнче, озын керфек! Күз төсеңнең дә үзең теләгәнен сайларга була! Әмма мондый мавыгуларның зарары турында күпләрегез белмидер дә әле. Яшьләр арасында конъюнктивит китереп чыгара торган сәбәпләр нәкъ менә төсле линза һәм керфек куйдыру икән ләбаса! Бердән, линзаларны киеп-салганда, үтә дә чиста булырга кирәклекне онытып җибәрәләр һәм күз эченә микроблар керә. Икенчедән, төсле линзаларның төс катлавы күзләргә һава керүне тоткарлый икән. Нәтиҗәдә көне буена күзләр талчыга, арый, кичкә бөтенләй кызарып ук чыга. Офтальмологлар мондый төр линзаларны бары тик бик кирәк




булганда, бәйрәмнәрдә һәм айга бер генә тапкыр кияргә яраганлыкны искәртә. Әле ул гына да түгел, күпчелек яшь-җилкенчәк, акча экономияләү максатыннан, линзаны билгеләнгән вакытыннан артыграк кияргә ярата. Ә бу исә күрүнең начараю тизлеген арттыра гына икән.

Ә инде ясалма керфекләргә килсәк, тагын да куркынычрак. Күп очракта алар сыйфатсыз була. Без аның бу ягына игътибар да бирмибез кебек: бары тик арзан булсын! Бөтен хикмәт керфек ябыштыра торган җилемдә. Андагы зарарлы микроблар күп очракта нәкъ менә күзләрнең начар күрүенә китерә. Шуңа да мондый матурлыкны көнгә 3-4 сәгатьтән артык киеп йөрергә ярамый икән.

Әлбәттә, һәрберебез матур булырга тели. Бу табигый халәт, ләкин сәламәт чакта гына чынчынлап матур булырга мөмкин икәнлекне онытып җибәрмәсәк иде. Юкка гына халык сәламәт тәндә – сәламәт акыл, димәгән бит!

• Дөнья үзебезнеке

# Күңелне дәвалау



**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Хәзерге көндә кирәкмәгән эмоциональ кичерешләрдән күп кеше интегә. Шуннан чыгу юлларын бергә эзләп карыйк әле. Үз-үзенә югары дәрәҗәдә ихтирамлы булырга һәм шәхси уңышларга ирешергә теләгән һәр кеше моны эшли ала.

Тәкъдим ителәсе хикәяләрнең һәркайсыннан рәхәтлек алып, ашыкмыйча, йөрәккә һәм аңга сеңәрлек итеп, җаныгызны тыңлап укыгыз. Шул ук вакытта үзегезгә сорау да бирегез: бу вакыйгаларның кайсы миңа көчлерәк йогынты ясады? Минем тормышыма ул ничек тәэсир итәргә мөмкин? Күңелем түрендә ул нинди хисләр уятты? Үзегезне шул геройлар хәленә куеп карагыз.

Хикәяләрнең кайберләре сезнең өчен башкаларыннан ныграк яңгырашлы булачак. Кайберләре яшерен мәгънә алыр. Елатыр яисә көлдерер. Монда турыдан-туры тик сезнең генә ничек төшенүегез мөһим һәм кабул итүегез кирәк.

Киләсе саннарда да дәвам ителәчәк бу хикәяләрне укыганчы, тагын бер кисәтү: аларны укып чыгарга гына түгел, ә аңларга тырышырга һәм үз тормыш тәҗрибәңнең бер өлеше итәргә. Әгәр дә сез укылган бер вакыйга турында танышларыгыз белән уртаклашырга телисез икән, кичекмәстән ул эшне башкарыгыз. Әгәр хикәя берәр кеше турында фикер уяткан икән, аңа шалтыратыгыз, үзегезнең уйларыгыз белән уртаклашыгыз.

## *Мәхәббәт – бердәнбер иҗади көч*

*Кешеләргә үзегезнең яратуыгызны бөтен җирдә сиздерегез, беренче чиратта – үз өегездә. Балаларыгызга, хатыныгызга яисә ирегезгә, күршеләрегезгә... Сезнең яныгыздан бер генә кеше дә аз гына булса да яхшырак һәм бәхетлерәк булмыйча китмәсен. Кешеләр сезнең күзләрегездә, йөзегездә һәм дусларча сәламләвегездә балкыган киң күңеллелекне күрсеннәр.*

*(Тереза Ана)*

***

*Бервакыт колледж профессоры социология төркемендә укучы студентларына Балтиморның хәерче кварталларында яшәүче 200 малай турында мәгълүмат җыярга тәкъдим итә. Ул алардан бу малайларның киләчәген бәяләүне дә сорый. Һәр очракта да студентлар бер үк нәрсә язалар: «Аның бернинди дә мөмкинлеге юк». 25 елдан соң социология буенча икенче бер профессор әлеге нәтиҗәләрне таба һәм укучылары белән бергә теге малайларның язмышларын өйрәнү проектын дәвам иттерә. Күчеп китү яисә вафат булу аркасында 20 сен санамаганда, 180 малайның 176 сы юрист, табиб, эшмәкәрләр буларак уңышлы гына эшли торган булып чыга.*

*Профессорның исе китә һәм сәбәпне ачыкларга була. Бәхеткә, бу кешеләр барысы да Балтимор районнарында яши һәм ул аларның һәрберсенә бер сорау белән мөрәҗәгать итә: «Үзегезнең уңышка ирешүегезне ничек аңлатыр идегез?» – ди. «Укытучым аркасында», – дигән охшаш җаваплар ала профессор.*

*Сүз барган әлеге укытучы исән була, аны эзләп табалар. Бу олы яшьтәге, тик элеккечә энергиясе ташып торган мөгаллимнән нинди магик формула ярдәмендә укучыларын хәерчелектән коткарып, аларга тормышта уңышларга ирешергә ярдәм итә алуы турында сорый профессор. Укытучының күзләре ялтырап китә һәм иреннәрендә йомшак кына елмаю барлыкка килә. «Бик гади, – дип җавап бирә ул. – Мин ул малайларны яраттым».*

*(Эрик Баттеруорт)*

(дәвамы бар)

(Дж. Кэнфилд һәм М.В.Хансен хезмәтләре файдаланылды).

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева, Б.Х.Ибраһимов, Э.Р.Ибраһимова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла